СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.06.2021 г. Заинск № 48

**«Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре милкендәге өченче зат хокукларыннан ирекле булган (хуҗалык карамагындагы хокуктан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга озак сроклы нигездә биләп торуга һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеге турында» 2017 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 4.1 өлеше, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 03 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре милкендәге өченче зат хокукларыннан ирекле булган (хуҗалык карамагындагы хокуктан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга озак сроклы нигездә биләп торуга һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеге турында» 2017 елның 15 ноябрендәге 92 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына 1 нче кушымтаны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, икътисадый үсеш һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**

Зәй муниципаль районы
Зәй шәһәре Советының
«18» 06.2021 ел
48 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре милкендәге өченче зат хокукларыннан ирекле булган (хуҗалык карамагындагы хокуктан, оператив идарә хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга озак сроклы нигездә биләп торуга һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт**

**ИСЕМЛЕГЕ**

| № п/п | Мөлкәтнең исеме | Бинаның гомуми мәйданы, кв.м | Урнашкан урыны, адресы | Бинаны билгеләнеше/җир кишәрлегенең категориясе | Бинаның/ җир кишәрлегенең кадастр номеры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Гараж җир кишәрлеге белән | 73,4 | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, «Энергетик-2» г/ш, № 168 | Торак булмаган бина/ торак пункт җирләре | 16:48:070104:2546/ 16:48:070104:13 |
| 2 | Гараж җир кишәрлеге белән | 144 | ТР, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, «Энергетик-2» г/ш, № 168 | Торак булмаган бина/ торак пункт җирләре | 16:19:070104:2582/ 1648:070104:14 |